**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2201**
**26.04.2022**

Яр Чаллы шәһәренең «Титан» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Титан» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 26 апрелендәге
2201 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Титан» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Массакүләм спорт чаралары оештыру һәм үткәрү | кеше | 100,00 |
| 2. | Чаңгыларны прокатка бирү (14 яшьтән зуррак балалар, зурлар) | комплект/сәгать | 200,00 |
| 3. | Чаңгыларны прокатка бирү (14 яшькә кадәрге балалар) | комплект/сәгать | 100,00 |
| 4. | Вибордны прокатка бирү | данә | 100,00 |
| 5. | Майка-номерны прокатка бирү | данә | 100,00 |
| 6. | Чаңгыларның шуа торган өслеген әзерләү (CH парафинын кулланып) | 1 пар | 200,00 |
| 7. | Чаңгы-роллерларны прокатка бирү (14 яшьтән зуррак балалар, зурлар) | комплект/сәгать | 200,00 |
| 8. | Чаңгы-роллерларны прокатка бирү (14 яшькә кадәрге балалар) | комплект/сәгать | 100,00 |
| 9. | Судьялар хезмәте | кеше | 2000,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева